М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов

# Туган тел
## (ТАТАР ТЕЛЕ)

### 4 сыйныф

МЕТОДИК ӘСБАП

*Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында*
*(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән)*
*эшләүче укытучылар өчен*

КАЗАН
2020

УДК 811.512.145 (075.2)
ББК 81.632.3я71
Ш92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде

**Шәкүрова, М. М.**

Ш92 Туган тел (татар теле). 4 сыйныф. Методик әсбап : башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен. / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. — Казан, 2020. — 36 б.

Методик әсбапта 4 сыйныфта программа материалының эчтәлеге, дәрес планы үрнәкләре бирелә, дәреслек белән эшләү тәртибе аңлатыла. Тематик планда ике юнәлеш өчен булган лексик, грамматик материал, укучыларның эшчәнлек төрләре, аларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә куелган таләпләр карала.

Әсбап башлангыч сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

© Г. Ибрагимов исем. ТӘһСИ, 2020
© М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов, 2020

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Укыту-методик комплекты татар телен туган тел буларак өйрәнә торган 4 сыйныф укучылары белән эшләүче укытучыларга тәкъдим ителә. УМК үз эченә уку әсбабы, электрон дәреслек, аудиоязмалар дискы һәм укытучылар өчен методик әсбапны ала.

Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч белем бирү этабында «Туган тел (татар теле)» предметы Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә туры китерелеп укытыла. Туган тел (татар теле) предметыннан белем бирүнең сыйфатын арттыру теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уяту һәм дөрес итеп сөйләшергә, укырга, язарга, фикерләргә өйрәтү таләп ителә.

4 сыйныфта «Туган тел (татар теле)» предметын укыту түбәндәге максатларны тормышка ашыруга юнәлтелә:

- укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыру, ягъни сөйләм мөмкинлекләреннән чыгып, туган телдә телдән һәм язмача аралашырга өйрәтү;
- балалар әдәбиятын, тарихын, фольклор әсәрләрен өйрәнү аша татар мәдәниятенә карата ихтирам хисләре тәрбияләү.

Әлеге максатларны тормышка ашыру өчен куелган бурычлар:

- Татарстан Республикасында төрле милләтләр өчен аралашу чарасы буларак татар теле турында мәгълүмат бирү;
- сөйләмә һәм язма телне үстерү максаты белән телнең грамматик нигезләрен үзләштерү;

- тел материалын үзләштерү барышында, аралашу очракларында, рольле уеннарда укучының шәхси сыйфатларын, игътибарын, фикерләү сәләтен, хәтерен һәм иҗадилыгын үстерү;
- предметка карата кызыксыну, уңай мотивация, туган телне өйрәнүгә мөмкинлек бирә торган махсус универсаль уку гамәлләре формалаштыру.

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

### Уку әсбабының структурасы

Уку әсбабы ике кисәктән тора. Һәр кисәк ике зур теманы үз эченә ала. Беренче кисәктә «Мин» һәм «Тирә-як, көнкүреш» темалары, Икенче кисәктә «Туган җирем» һәм «Татар дөньясы» темалары урнаштырылды.

### Темаларның төзелеше

Һәр тема бертөрле калыпка салынды. Бер тема берничә дәресне үз эченә ала.

1) Укучылар ярдәме белән тема әйтелә. Дәреснең максаты, бурычлары формалаштырыла.
2) Грамматик материал өйрәнелә.
3) Яңа теманы ныгыту өчен, биремнәр эшләнә. Шулар арасында мәҗбүри рәвештә халык авыз иҗаты үрнәкләре белән бәйле эш тәкъдим ителә.
4) Парларда эш башкарыла.
5) Укучылар ярдәме белән Куян күчтәначендә биреләчәк тема билгеләнә. Темага керү өчен, бирем эшләнә.
6) Яңа тема аңлатыла (Куян күчтәнәче).
7) Куян кучтәначен ныгыту өчен биремнәр башкарыла.
8) Теманы йомгаклауга күнегүләр, логик биремнәр, кызыклы эш төрләре башкарыла.

Уку әсбабы ике юнәлешне (база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләрне) үз эченә ала. Туган телне тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган материал зәңгәрсу фон белән

бирелде. Әмма база өлешен өйрәнүче укучылар белән эшләүче укытучылар, балаларның белем дәрәҗәләреннән, мөмкинлекләреннән чыгып, әлеге биремнәрне дә эшли алалар. Ике юнәлешнең бер китапта бирелүе көчлерәк укучылар белән аерым якын килеп эшләү мөмкинлеге тудыра.

Уку әсбабында аерым тема эчендә ике юнәлеш өчен дә бер тексттан алынган берничә өзек кулланыла. Бу база өлешен өйрәнүче укучыларда текстның дәвамын уку теләге тудыру өчен дә отышлы.

## Предметның эчтәлеге

Дәреслек дүрт лексик теманы үз эченә ала.

**«Мин»** темасында җәйге ял, сәяхәт итү, кешеләргә, җәнлекләргә яхшылык эшләү, дуслык, галәм турында сөйләшү, текстлар белән эшләү, әңгәмәләр кору күз алдында тотыла.

**«Тирә-як, көнкүреш»** темасын өйрәнгәндә, мифологик образлар һәм әкият геройлары (су иясе, су анасы, Сусылу, Суык бабай, Кыш бабай, Кар кызы, Шүрәле һ. б.) турындагы текстлар белән эш алып барыла.

**«Туган җирем»** темасын өйрәнгәндә, табигать, экологияне саклау, дөньядагы кызыклы вакыйгалар, Россиянең күренекле шәһәрләре, аларның тарихы, андагы күренекле урыннар турындагы текстлар белән эш оештырыла. Бөек Ватан сугышы, солдатларның батырлыклары темаларына укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәре камилләштерелә. Герой шагыйрь Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турында әңгәмә үткәрелә.

**«Татар дөньясы»** темасында татар авылының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында сүз йөртелә, укучыларның сөйләм теле баетыла.

**Фонетика һәм орфоэпия.**

Татар теленең сузык һәм тартык авазлар системасы. Авазларның саны. Татар теленең үзенчәлекле авазлары [ә], [ө], [ү], [w], [ғ], [қ], [х], [ч], [җ], [ң], [һ], аларны дөрес әйтү. Сингармонизм законы.

Басым һәм аның төрләре.

Транскрипция.

Татар теленең орфоэпик сүзлеге белән эшләү.

Язуда е хәрефе белән белдерелә торган авазлар. Сингармонизмның төрләре.

Логик басым.

Сүзгә фонетик анализ ясау.

**Графика, орфография.**

Графика һәм орфография турында гомуми мәгълүмат. Алынма сүзләрнең дөрес язылышы.

**Лексикология.**

Сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Текстларда күп мәгънәле сүзләрнең кулланылуы. Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе.

Татар теленең сүзлек составы. Алынма сүзләр.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге белән эшләү.

Омонимнар.

Татар телендә гарәп-фарсы алынмалары.

**Сүз ясалышы.**

Сүз ясалышы һәм төзелеше турында гомуми мәгълүмат. Тамыр һәм кушымча. Тамырдаш сүзләр.

Кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясау.

Сүзнең нигезе. Сүзне төзелеше ягыннан тикшерү.

*-лык/-лек* кушымчасы ярдәмендә исем сүз төркеме ясалу.

**Морфология.**

Сүз төркемнәре. Мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәре.

Исем сүз төркеме. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Җанлы һәм җансыз предметлар.

Исемнәрнең килеш белән төрләнүе.

Сыйфат сүз төркеме. Сыйфат дәрәҗәләре.

Алмашлык. Зат алмашлыклары. Күрсәтү алмашлыклары. Сорау алмашлыклары.

Сан. Сан төркемчәләре.

Фигыль. Заман категориясе. Хәзерге заман. Үткән заман һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр. Хикәя фигыльнең зат-сан

белән төрләнүе. Боерык фигыль. Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы.

Ялгызлык исемнәрне күплек санда куллану.

Синоним сыйфатлар. Антоним сыйфатлар.

Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнүе. Алмашлыкларның сөйләмдә кулланылуы.

Саннарның килеш белән төрләнүе.

Фигыльнең нигезе. Фигыльнең билгесез үткән заман формасы. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы. Вакытны белдерә торган сүзләр.

**Синтаксис.**

Сүз. Сүзтезмә. Җөмлә.

Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләнең иярчен кисәкләре.

Иянең күплек сандагы исемнәр белән белдерелүе.

**Пунктуация.**

Татар телендә тыныш билгеләре. Орфографик сүзлек белән эш.

## ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәреснең темасы | | Сәг. саны | Белем, эш осталыгы һәм күнекмәләренә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| | Лексик тема | Грамматик тема | | |
| | **МИН** 22/11 сәгать | | | |
| 1 | Җәйге мажаралар | 1–3 нче сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау | 3/1 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Алдагы сыйныфларда өйрәнгән материалны кабатлау. Диалоглар төзү, үзеңнең җәйне ничек уздыруың турында сөйләү.<br><br>Татар теленең фонетикасы, лексикасы һәм грамматикасына караган материалларны кабатлау. Проблемалы ситуацияне чишү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 6–9, 12–14 битләр. 9–12, 13 битләр. |
| 2 | Мин сәяхәттә | Татар теленең үзенчәлекле авазлары | 4 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Татар теленең |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Язуда е хәрефе белән белдерелә торган авазлар | 1 | үзенчәлекле сузык һәм тартык авазларын белү. Сузык авазлар системасын белү.<br><br>Кайсы авазларның, сүздәге урынына карап, язуда *е* хәрефе белән белдерелүен билгеләү.<br>Татар әдәби теле нормаларын белү, сыйныфташларыңның сөйләмен бәяли белү.<br>Сәяхәтче бака мисалында мактануның тискәре сыйфат булуын ачыклау.<br>Проблемалы ситуация чишү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 15–19, 21–23 битләр.<br>19–21 битләр. |
| 3 | Иҗади дәрес | | 1 | |
| 4 | Яхшылык кире кайта | Сингармонизм законы | 1 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Татар теленең сузык авазлары системасын белү. Сузыкларның иҗек барлыкка китерүдәге ролен |
| | | Сингармонизмның төрләре | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | билгеләү, сингармонизм законын белү.<br><br>Сузыклар гармониясенең төрләрен белү. Укыган текстның эчтәлеген аңлау. Логик басымны дөрес билгеләү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 24–25, 27 битләр. 25–27 битләр. |
| 5 | Сочинение | | 1 | |
| 6 | Текст белән эш | | 2/1 | Аудиотекст белән эшләү. Тексттан кирәкле мәгълүматны табу. Ситуацияләрдә сөйләм этикеты нормаларын дөрес куллану.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 28–33 битләр. |
| 7 | Нәрсә яхшы, нәрсә начар? | Басым һәм аның төрләре | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сузык авазларның иҗек барлыкка китерүдәге ролен аңлау. Сүз басымын дөрес билгеләү. |
| | | Логик басым | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Якыннарга, дусларга бүләк сайлау турында әңгәмә кору.<br><br>Басымның төрләрен белү. Логик басымны билгеләү. Татар әдәби теле нормаларын белү, аларның сөйләмдә үтәлүен күзәтү, бәяләү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 34–37, 40 битләр.<br>38–40 битләр. |
| 8 | | Транскрипция | 1 | Сүзләрнең транскрипциясен язу.<br><br>Сүзгә фонетик анализ ясау.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 41–43 битләр. |
| | | Сүзгә фонетик анализ ясау | 2 | |
| 9 | Кабатлау | | 1/1 | Аудиотекст белән эшләү. Тыңлаган текстны уку. Өйрәнгән материалны кабатлау.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 44–45 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Контроль эш | | 1 | |
| 11 | Фантастик әсәрләр | Алынма сүзләр һәм аларның язылышы | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Тексттан рус теленнән һәм аның аша кергән сүзләрне табу. Космос турында сөйләшү.<br>Гарәп-фарсы алынмаларын белү. Текстлар белән эшләү. Сөйләм этикеты нормаларын саклап, төрле ситуацияләргә диалоглар төзү.<br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br>Дәреслек, 1 кисәк: 46–50, 53 битләр. 50–53 битләр. |
| | | Татар телендә гарәп-фарсы алынмалары | 2 | |
| 12 | Кабатлау | | 2/1 | Аудиотекст белән эшләү. Язмача һәм телдән күнегүләр башкару. Өйрәнгән материалларны кабатлау.<br>Дәреслек, 1 кисәк: 54–59 битләр. |
| **ТИРӘ-ЯК, КӨНКҮРЕШ**<br>**9** / **4** сәгать | | | | |
| 13 | Һөнәрле кеше үлмәс | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сүзнең лексик |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр | | мәгънәсен аңлау.<br>Туры мәгънәдә һәм күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүзләрне билгеләү.<br>Әдәби тексттан күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүзләрне табу.<br><br>Сөйләмдә синоним, антоним, омоним сүзләрне куллану.<br>Проблемалы ситуацияне чишү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 62–66 битләр.<br>66–67 битләр. |
| | | Омонимнар | 1 | |
| 14 | Татар теленең аңлатмалы сүзлеге белән эшләү | | 1 | Аңлатмалы сүзлек ярдәмендә сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау. |
| 15 | Су иясе | Сүз төзелеше | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Сүзнең тамырын, кушымчаларын билгеләү. Сүз ясагыч һәм форма ясагыч кушымчаларны аеру.<br>Тамырдаш сүзләр төшенчәсе белән танышу. |
| | | Сүзнең нигезе<br>Сүз төзелешен тикшерү | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Татар телендә сүзләргә кушымчалар ялгану үзенчәлеген, тәртибен белү. Телдән һәм язмача сүзләрнең төзелешен тикшерү. Проблемалы ситуацияне чишү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 68–71, 74 битләр. 72–74 битләр. |
| 16 | Кабатлау | | 2/1 | Аудиотекст белән эш. Тыңлаган текстны уку. Лексикологиядән өйрәнгән материалны кабатлау.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 75–79 битләр. |
| 17 | Кыш бабайга хат язу | | 1 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Кыш бабайга хат язу.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| 18 | Контроль эш | | 1 | |

| ТУГАН ҖИРЕМ<br>31 / 16 сәгать | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19 | Экология | Сүз төркемнәре | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Сүз төркемнәрен белү. Сүзләрнең кайсы сүз төркеменә керүен билгеләү.<br>Сүз төркемнәрен мөстәкыйль һәм ярдәмлек сүз төркемнәренә аеру.<br>Туган илебезнең экологисе турында әңгәмәдә катнашу.<br><br>Сыйфатлардан исемнәр ясау.<br>Тыңлаган текстның эчтәлеген аңлау.<br>Текстның эчтәлегенә караган сорауларга җаваплар бирү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 4–7, 9 битләр.<br>7–8 битләр. |
| | | *-лык/-лек* кушымчасы ярдәмендә исем сүз төркеме ясалу | 1 | |
| 20 | Җир шары тирәли сәяхәт | Исем сүз төркеме | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Исем сүз төркеменә кергән сүзләрне тану, мәгънәләрен һәм сөйләмдә кулланылу |
| | | Ялгызлык исемнәрне күплек санда куллану | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | үзенчәлекләрен белү. Кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә торган җанлы һәм җансыз исемнәрне аеру. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне билгеләү.<br>Исемнәрнең күплек санын ясый торган кушымчаларны белү. Күплек санда кулланылган ялгызлык исемнәрнең мәгънәләрен ачыклау. Чын дуслык турында әңгәмәдә катнашу.<br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br>Дәреслек, 2 кисәк: 10–13 битләр.<br>12 битләр. |
| 21 | Иҗади дәрес | | 1 | |
| 22 | Россиядәге күренекле шәһәр | Сыйфат дәрәҗәләре | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Сыйфат сүз төркемен тану. Сыйфат дәрәҗәләрен белү. Сыйфатларның төрле дәрәҗәләрен ясау.<br>Санкт-Петербург шәһәренең күренекле урыннары турында сөйләү. |
| | | Синоним сыйфатлар<br>Антоним сыйфатлар | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Сыйфатларның сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен ачыклау.<br><br>Үзара синоним һәм антоним булган сыйфатларны белү. Үзлектән укыган текстны аңлау. Тексттан кирәкле мәгълүматны табу.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 14–17, 20 битләр. 17–19 битләр. |
| 23 | Текст белән эш | | 2/1 | Аудиотекст белән эшләү. Тексттан кирәкле мәгълүматны табу. Ситуацияләрдә сөйләм этикеты нормаларын дөрес куллану.<br><br>План ярдәмендә текстның эчтәлеген сөйләү. Өйрәнгән кагыйдәләрне гамәлдә дөрес куллану.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 21–25 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 24 | Габдулла Кырлай авылында | Алмашлык Зат алмашлыклары | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Алмашлыклар, зат алмашлыклары турында гомуми күзаллау булдыру. Берлек һәм күплек сандагы 1, 2, 3 зат алмашлыкларын сөйләмдә дөрес куллану. |
| | | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнүе | 1 | Зат алмашлыкларын килешләр белән төрләндерү. Габдулла Тукай турында әңгәмәдә катнашу.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 26–28, 30 битләр. 28–30 битләр. |
| 25 | Вакытны чәчәкләр әйтә | Күрсәтү һәм сорау алмашлыклары | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Күрсәтү һәм сорау алмашлыкларын тану. Аларны сөйләмдә куллану. |
| | | Алмашлыкларның сөйләмдә кулланылуы | 1 | Алмашлыкларның мәгънәләрен ачыклау, ясалу үзенчәлекләрен белү. Аларны сөйләмдә дөрес файдалану. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Төрле чыганаклар ярдәмендә үсемлекләрнең вакытны белдерү үзенчәлекләрен ачыклау.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 31–33, 35 битләр.<br>33–34 битләр. |
| 26 | Сочинение | | 1 | |
| 27 | Йорт иясе | Сан. Сан төркемчәләре | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сан сүз төркемен билгеләү. Алар турында гомуми күзаллау булдыру, мәгънәләрен һәм кулланылу үзенчәлекләрен ачыклау. Йорт иясе турындагы мифны уку.<br><br>Саннарны килешләр белән төрләндерү. Тыңлаган текстның мәгънәсен аңлау. Текстның эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, әңгәмә уздыру.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. |
| | | Саннарның килеш белән төрләнүе | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 36-38, 39-40 битләр. 38 бит. |
| 28 | Диктант | | 1 | |
| 29 | Начарлык-тан эз кала | Боерык фигыль | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Фигыль сүз төркемен белү. Аның төп мәгънәсен һәм кулла-нылуын ачыклау. Бо-ерык фигыльнең яса-лу үзенчәлеге, мәгънә үзенчәлекләрен белү.<br><br>Фигыльләрнең ниге-зен билгеләү. Яхшы һәм начар гамәлләр турында сөйләшү. Мәкальләрне уку һәм аларның мәгънәләрен ачыклау.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 41–43 битләр. 44 бит. |
| | | Фигыльнең нигезе | 1 | |
| 30 | Кабатлау | | 1 | Аудиотекст белән эшләү. Тексттан |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | кирәкле мәгълүматны табу. Ситуацияләрдә сөйләм этикеты нормаларын дөрес куллану. |
| 31 | Контроль эш | | 1 | |
| 32 | Ил солдаты | Хәзерге заман хикәя фигыль | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Хәзерге заман хикәя фигыльнең ясалу үзенчәлекләрен, аларның хәзерге, үткән һәм киләчәк заман формаларын белү. Хәзерге заманда фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү.<br><br>Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасын ясау. Хикәя фигыльләрне юклыкта зат-сан белән төрләндерү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 45–47, 49 битләр. 47–49 битләр. |
| | | Хикәя фигыльнең юклык формасы. | 1 | |
| 33 | Муса Җәлил | Үткән заман хикәя фигыль | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Үткән заман хикәя фигыль |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Фигыльнең билгесез үткән заман формасы | 1 | формасын тану, ясалу үзенчәлеген белү. Сөйләмдә дөрес файдалану.<br>Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турында әңгәмәдә катнашу.<br><br>Фигыльнең билгесез үткән заман формасын тану, әлеге форманың ясалу, сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен белү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 50–52, 53 битләр.<br>52–53 битләр. |
| 34 | Бөек Ватан сугышында | Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү.<br>Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасын ясау.<br>Бөек Ватан сугышы турында әңгәмәдә катнашу.<br><br>Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасын ясау. Аларны зат-сан белән төрләндерү. |
| | | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 54–55, 57 битләр. 55–57 битләр. |
| 35 | Батырлыкта матурлык | Фигыльнең киләчәк заман формасы | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Киләчәк заманның белдерелү үзенчәлекләрен ачыклау. Фигыльләрне сөйләмдә куллану. Солдатларның сугышта күрсәткән батырлыклары турында сөйләшү.<br><br>Вакыт рәвешләрен тану (терминны атамый гына). Проблемалы ситуацияне чишү.<br><br>Дәреслекнең сүзлеге белән эшләү. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 58–61, 62–63 битләр. 61–62 битләр. |
| | | Вакытны белдерә торган сүзләр | 1 | |
| 36 | Кабатлау | | 1/1 | Аудиотекст белән эшләү. Текстның темасын, төп фикерен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | билгеләү. Өйрәнелгән лексик һәм грамматик материалны кабатлау.<br><br>Картина ярдәмендә текст төзү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 64–68 битләр. |
| **ТАТАР ДӨНЬЯСЫ**<br>**6 / 3 сәгать** | | | | |
| 37 | Ишегалдында | Җөмләнең баш кисәкләре | 1 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Җөмләнең баш кисәкләре ия белән хәбәрне табу.<br><br>Җөмләнең баш кисәге ия турында күзаллау булдыру. Иянең күплек сандагы исем белән белдерелү очрагын өйрәну. Авыл, андагы тормышның үзгәрүе турында әңгәмәдә катнашу.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 70–71, 73–64 битләр. 71–72 битләр. |
| | | Ия | 1 | |
| 38 | Йорт янында бакчада | Җөмләнең иярчен кисәкләре | 2/1 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табу. Җөмләдә сүзләр һәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | сүзтезмәләр арасындагы бәйләнешне ачыклау.<br><br>Проблемалы ситуация белән эшләү. Тәрҗемә итү күнекмәләре булдыру. Татар утары турында әңгәмәдә катнашу.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 75–77, 78–79 битләр. 77–78 битләр. |
| 39 | Кабатлау | | 1 | Аудиотекст белән эшләү. Текстның темасын, төп фикерен билгеләү. Өйрәнелгән лексик һәм грамматик материалны кабатлау.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 80–83 битләр. |
| 40 | Гомуми кабатлау | | 1/1 | Тыңлаган һәм укыган текст белән эшләү. Ел дәвамында өйрәнгән материалны (фонетика, лексикология, морфология һәм синтаксис) кабатлау, кагыйдәләрне гамәлдә куллану.<br><br>Рәсем ярдәмендә текст төзеп язу.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 84–88 битләр. |
| 41 | Контроль эш | | 1 | |

# ДӘРЕС ПЛАННАРЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

## Лексик тема: ҖӘЙГЕ МАҖАРАЛАР
**3 / 1 сәгать**

### 1 дәрес

**Тема:** 1–3 нче сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау. Фонетика

**Максат һәм бурычлар:** Уку бурычын дөрес билгеләү; алдагы сыйныфларда өйрәнгән материалны кабатлау; диалоглар төзү, үзеңнең җәйне ничек уздыруың турында сөйләү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

**Дәрес этаплары**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: үзеңнең җәйне ничек уздыруың турында сөйләү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Сузык авазлар.

2) Тойгылы һәм сорау җөмләләр.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Рәсемне карау. Бирелгән сүзләр ярдәмендә хикәя төзеп сөйләү (1 күнегү, 6 бит).

2) Текстны уку. Сораулар һәм җаваплар (2 күнегү, 7 бит).

3) Тексттан тойгылы һәм сорау җөмләләрне табып уку (2 күнегү, 2–1, 7 бит).

4) Хаталы җөмләләрне дөресләп язу (2 күнегү, 2–2, 8 бит).

5) Сүзләрдәге авазларны кайсы хәрефләр белдерүен үрнәктәгечә язу (2 күнегү, 2–3, 8 бит).

6) Сүзләрдә калын сузыкларны сызу, җөмләне күчереп язу (2 күнегү, 2–4, 8 бит).

7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 2 дәрес

**Тема:** Фонетика, лексикологиядән алдагы сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау

**Максат һәм бурычлар:** Уку бурычын дөрес билгеләү; алдагы сыйныфларда өйрәнгән материалны кабатлау; тиен малае Җитезнең кышка ничек әзерләнүе турында сөйләшү, диалоглар төзү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: авазлар һәм хәрефләр; текстны искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Авазлар һәм хәрефләр.
2) Текст.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Җөмлә чикләрен билгеләү. Җөмләләрдән ике текст төзеп язу (2 күнегү, 2–5, 8 бит).
2) Мәкальләрнең башын ахыры белән парлап уку (3 күнегү, 9 бит).
3) Сүзләргә кушымчалар ялгап, җөмләләрне күчереп язу (4 күнегү, 4–2, 10 бит).
4) Җөмләләрдә кабатланган сүзләрне табу һәм башка сүзләр белән алыштырып язу (7 күнегү, 7–4, 13 бит).
5) Русча-татарча сүзлек ярдәмендә башваткычны чишү (8 күнегү, 14 бит).
6) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.
7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 3 дәрес

**Тема:** Сүз ясалышыннан алдагы сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау

**Максат һәм бурычлар:** Уку бурычын дөрес билгеләү; алдагы сыйныфларда өйрәнгән материалны кабатлау; «Табигать — үзе табиб» темасы ярдәмендә диалог төзү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: тартык авазлар турында сөйләшү; кушымчалар ялгауны искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Тартык авазлар, кушымчалар, җөмләнең баш кисәкләре.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Шигырьне уку (7 күнегү, 12 бит).

2) Сүзләрдәге зәңгәр төс белән бирелгән хәрефләрнең нинди авазларны белдерүен ачыклау (7 күнегү, 7–1, 13 бит).

3) Бирелгән төркемнәргә сүзләр язу (4 күнегү, 4–3, 10 бит).

4) Сүзләргә тиешле кушымчаларны ялгап язу (7 күнегү, 7–2, 13 бит).

5) Шигырьдән хәбәр белән тәмамланмаган җөмләләрне табып уку (7 күнегү, 7–3, 13 бит).

6) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 4 дәрес

**Тема:** Лексикология һәм грамматикага караган материалны кабатлау

**Максат һәм бурычлар:** Татар теленең лексикологиясе һәм грамматикасына караган материалларны кабатлау; дуслары тиен малаена гөмбә, чикләвек җыярга булышулары турында диалоглар төзү; проблемалы ситуацияне чишү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: лексикология һәм грамматиканы искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Синонимнар һәм антонимнар.
2) Исемнәр, сыйфатлар һәм фигыльләр.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Текстның дәвамын рольләргә бүлеп уку (4 күнегү, 9 бит).

2) Кайсы мәкаль текстның эчтәлегенә туры килә?(4 күнегү, 4–1, 10 бит).

3) Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең синонимнарын һәм антонимнарын табып уку (5 күнегү, 11 бит).

4) Исемнәргә сыйфатлар һәм фигыльләр уйлап язу (6 күнегү, 11 бит).

5) Айдар дөрес эшлиме?

Фикереңне дәлилләп сөйләү (6 күнегү, 12 бит).

6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## Лексик тема: МИН СӘЯХӘТТӘ

**4 / 1 сәгать**

### 5 дәрес

**Тема:** Татар теленең үзенчәлекле сузык һәм тартык авазлары

**Максат һәм бурычлар:** «Мин сәяхәттә» темасы турында сөйләшү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; уку бурычын дөрес билгеләү; татар теленең үзенчәлекле авазларын белү, сузык һәм тартык авазларны искә төшерү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Сүзләрне уку. Бу тартык авазлар рус телендә очрыймы?(9 күнегү, 15 бит).

3) Әңгәмә: татар теленең үзенчәлекле авазларын искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Татар теленең үзенчәлекле авазлары, сузык һәм тартык авазлар.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Сазлыктагы бака» текстын рольләргә бүлеп уку (10 күнегү, 15 бит).

2) Карта белән эш (10 күнегү, 10–1, 16 бит).

3) Татар телендә генә булган тартык авазларның асларына сызу (10 күнегү, 10–2, 16 бит).

4) Калын һәм нечкә сузык авазларны парлап язу (10 күнегү, 10–3, 16 бит).
5) Табышмакларның җавабын табу (11 күнегү, 17 бит).
6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**
1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 6 дәрес

**Тема:** Татар теленең үзенчәлекле сузык авазлары

**Максат һәм бурычлар:** «Мин сәяхәттә» темасы турында сөйләшүне дәвам итү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; татар теленең үзенчәлекле сузык авазларын искә төшерү, ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: сузык авазларны искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Сузык авазлар һәм аларның әйтелеше.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Бака сәяхәте» текстының дәвамын уку. Сораулар һәм җаваплар (18 күнегү, 21 бит).

2) Сүзләрне дөрес уку. Татар телендә [о], [ы], [э], [ө] авазларының әйтелешенә игътибар итү (12 күнегү, 12–1, 18 бит).

3) Рус сүзләрендә [$\bar{о}$], [$\bar{ы}$], [$\bar{э}$] авазларын дөрес әйтү (12 күнегү, 12–2, 18 бит).

4) Сүзләрдә төшеп калган хәрефләрне язу (13 күнегү, 20 бит).

5) Хаталы җөмләләрне дөресләп язу (12 күнегү, 12–3, 18 бит).
6) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.
7) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**
1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 7 дәрес

**Тема: Татар теленә генә хас авазларны дөрес әйтү**

**Максат һәм бурычлар:** «Мин сәяхәттә» темасына сөйләшүне дәвам итү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү; татар теленең үзенчәлекле авазларын искә төшерү, ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: татар теленең үзенчәлекле тартык авазларын искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Тартык авазлар һәм аларның әйтелеше.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү:**

1) Геройларга туры килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне табып уку. Татар теленең үзенчәлекле авазларын табу (12 күнегү, 12–4, 19 бит).

2) Рәсемнәрне карау. Әкият эчтәлегенә туры китереп әйтү (12 күнегү, 12–5, 19 бит).

3) Рәсемнәр ярдәмендә әкиятнең эчтәлеген сөйләү (12 күнегү, 12–5, 19 бит).

4) Бакага кайсы киңәшләр файдалы булыр? Дөрес булган җөмләләрне генә сайлап уку. (15 күнегү, 21 бит).

5) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.

6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 8 дәрес

**Тема: Сузык һәм тартык авазларны кабатлау**

**Максат һәм бурычлар:** «Мин сәяхәттә» темасына сөйләшүне дәвам итү, укучыларның логик фикерләү сәләтләрен үстерү, рәсемле башваткычлар чиштерү; татар теленең үзенчәлекле авазларын өйрәнүне ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

**Дәрес этаплары**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: укучыларның логик фикерләү сәләтләрен үстерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Татар телендә сузык һәм тартык авазлар.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Сүзләрне тәрҗемәләре белән парлап уку (16 күнегү, 22 бит).

2) *Бака* сүзен *бора*га әйләндерү (17 күнегү, 22 бит).

3) Сүзләрне үрнәктәгечә язу. Калын сузык авазлар астына яшел, нечкә сузык авазлар астына сары карандаш белән сызу. (12 күнегү, 12–8, 20 бит).

4) Рәсемле башваткычны чишү (18 күнегү, 23 бит).

5) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.
6) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү:**
1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 9 дәрес

**Тема: Язуда *е* хәрефе белән белдерелә торган авазлар**

**Максат һәм бурычлар:** татар әдәби теле нормаларын белү, кайсы авазларның, сүздәге урынына карап, язуда *е* хәрефе белән белдерелүен билгеләү; башкаларның сөйләмен бәяли белү; сәяхәтче бака мисалында мактануның тискәре сыйфат булуын ачыклау; проблемалы ситуацияне чишү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: кайсы авазларның, сүздәге урынына карап, язуда *е* хәрефе белән белдерелүен искә төшерү.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Татар әдәби теле нормалары; сузык авазлар системасы.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Хаталарны табып дөресләү. Калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны парлап әйтү (12 күнегү, 12–6, 19 бит).

2) *Кечкенә, черки, елга, каен* сүзләрендә е хәрефенең нинди авазлар белдерүен ачыклау (12 күнегү, 12–7, 19 бит)

3) Ситуация белән танышу, сәхнәләштереп күрсәтү. Сораулар һәм җаваплар (14 күнегү, 20–21 битләр).

4) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эшләү.
5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**
1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

Учебное издание

**Шакурова** Муслима Магесумовна
**Гиниятуллина** Лилия Миннулловна
**Хисамов** Олег Ришатович

**РОДНОЙ ЯЗЫК**
**(татарский язык)**

4 класс

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
начального общего образования
(для изучающих татарский язык как родной)

*Допущено Министерством образования и науки*
*Республики Татарстан*

Казань. Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова. 2020
*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Шәкүрова** Мөслимә Мәгъсүм кызы
**Гыйниятуллина** Лилия Миңнулла кызы
**Хисамов** Олег Ришат улы

**ТУГАН ТЕЛ**
**(татар теле)**

4 сыйныф

Методик әсбап
башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән*
*министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән*

Художник *А. Б. Шляпкин*
Верстка *Э. Ф. Нурмухаметовой*

Подписано в печать с оригинал-макета 20.04.2020.
Формат 60 x 84 1/16.